СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 октябрь, 2025 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 92 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елныж 29 декабрендщге 1743 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Ямаширмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 18 сентябрендәге 1332/о боерыгы раслануга бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 92 номерлы карары (21.11.2023 № 346 редакциясендә) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында мәгълүматны актуальләштерүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов